**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**БОЕРЫГЫ**

13.05.2023 № 166

**Татарстан Республикасында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб составына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб төзү турында» 2022 елның 29 мартындагы 125 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 29 апрелендәге 150 номерлы, 2022 елның 6 июлендәге 226 номерлы, 2022 елның 9 сентябрендәге 294 номерлы, 2022 елның 26 декабрендәге 416 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында социаль-икътисадый тотрыклылыкны тәэмин итү буенча оператив штаб (алга таба – Оператив штаб) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Оператив штаб составыннан И.М. Галиевны, Е.Л. Горюнованы, Ф.Р. Закировны, Т.Р. Минушевны, М.Н. Садыйковны, С.В. Сергеевны чыгарырга;

Оператив штаб составына түбәндәгеләрне кертергә:

Аманов Рөстәм Ринат улын – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы көрәшү идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Вафин Эдуард Яфас улын – Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесен (килешү буенча);

Миңнуллин Марсель Мансур улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Миңнуллина Талия Илгиз кызын – Татарстан Республикасының инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесен;

Трущин Максим Владимировичны – янгын күзәтчелеге буенча Татарстан Республикасы баш дәүләт инспекторы – Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Оператив штаб әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.Н. Миңнехановның – «Татарстан Республикасы Рәисе, Оператив штаб рәисе»;

Ф.С. Абдулганиевның – «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе»;

Э.И. Гафуровның – «Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе башлыгы урынбасары – идарәнең лицензия-рөхсәт көгазьләре бирү үзәге башлыгы (килешү буенча)»;

А.И. Нәфыйгинның – «Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе».

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**